РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ул.Школьная, д.8, с.Карамышнво, 423119

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 8 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс (84396) 4-22-23 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

№119 18 сентябрь 2019ел

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, «Җирле референдум турында " 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Кармыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кармыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2009 елның 18 сентябрендә кабул ителгән 35 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Киләсе мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә: «Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәкләрдән тыш Кармыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

- Кармыш, Яшәүче авылларындагы җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга җәйге һәм кышкы чордагы чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү, юлларны грейдлаштыру, кышын урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт күрсәтүгә түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәт күрсәтү);

- Кармыш, Яшәүче авылларында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, урам утларын кулланган өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар (хезмәтләр күрсәтү) сатып алу;

- Кармыш, Яшәүче бистәләрендәге урам юл челтәрендә чокырлар ямау буенча эшләр башкару өчен кирәкле материаллар (хезмәтләр күрсәтү) сатып алу;

- Кармыш һәм Яшәүче бистәләрендәге торак пунктларда скважиналарны лицензияләүгә , су экспертизасына һәм анализлауга түләү;

- Кармыш, Яшәүче бистәләрендә зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, тоту (урнаштыру), зиратларны ремонтлау һәм буяу, урналар урнаштыру, коры-сарыдан чистарту, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар алу һәм башкарылган эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

- 2015 елда үзара салым акчаларыннан калган 148010 сумны кулланырга.

2015 елгы референдум йомгаклары буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җыелган акчаларны әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен юллау белән килешәсезме

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карар мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Кармыш авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Фәтхетдинов И.И.